ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«26» ноябрь 2021 ел № 152-р

2021 елның өченче кварталы өчен яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең тармак белгечләренә бер мәртәбә түләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 15 ноябрендәге 2318-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә:

Төп ставка буенча хезмәт хакын күтәрүгә бәйле чаралар нигезендә бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашырырга:

1. Биләп торган төп ставка буенча эш хакын күтәрүгә бәйле чаралар нигезендә бер мәртәбә түләүне гамәлгә ашырырга
- яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең тармак белгечләренә (тышкы ике эштә эшләүчеләрдән, ХЭС җитәкчеләреннән һәм хезмәткәрләреннән, балаларның җәйге ялын тәэмин итүче хезмәткәрләрдән тыш).

2. Әлеге күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән яңа кабул ителгән хезмәткәрләргә 2021 елның өченче кварталында фактта эшләнгән вакыт нигезендә түләүне гамәлгә ашырырга.

3. “Әгерҗе муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе” муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге күрсәтмәне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**